ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                    КАРАР

______________                 с. Верхний Услон                 ______________

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябреннән 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсе мобилизацияләнгән баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү хакында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 3 ноябреннән 1358 карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 1213 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп программасын гамәлгә ашыручы муниципаль мәгариф оешмаларында «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябреннән 647 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә ата-аналарның (законлы вәкилләрнең) берсе мобилизацияләнгән баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү хакында» Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 3 ноябреннән 1358 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарның бер ата-анасы (законлы вәкилләре) махсус хәрби операциядә катнашкан ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренең балаларын Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирүнең төп программасын гамәлгә ашыручы

муниципаль мәгариф оешмаларында карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итү турында".

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, Россия Федерациясе Милли гвардиясендә хезмәт итүче хәрби хезмәткәрләр, Татарстан Республикасында формалашкан «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында хәрби хезмәт үтүче гражданнар, махсус хәрби операция барышында хәрби бурычларны ирекле үтәүче гражданнар, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр Министрлыгы, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәткәрләре арасыннан махсус хәрби операция үткәрү зонасына командировкага җибәрелгән гражданнар арасыннан бер ата-анасы (законлы вәкилләре) махсус хәрби операциядә катнашкан ата-аналардан (законлы вәкилләрдән), шулай ук махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаиләләренең балаларын карау һәм тәрбияләү өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итергә.

3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 ноябреннән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.
3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе И.И. Шакиров

Әзерләде һәм бастырып чыгарды
Р.Х. Яковлева
5 нөсхәдә